СОВЕТ
ЯНГА - САЛСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д.18, с. Янга-Сала,
Арский муниципальный район, 422011

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢАСАЛА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 18 йорт, Яңасала авылы,
Арча муниципаль районы, 422011

Тел. (84366) 57-2-10, факс (84366) 57-2-10. E-mail: Yns.Ars@tatar.ru www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«05» июль 2019 ел** **№ 2**

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендә чыккан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2131-ФЗ номерлы законы, Яңасала авыл җирлеге Уставы һәм хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашуда Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеге халкының хокукларын тәэмин итү максатында 22.10.2018 чыгарылган 11 нче номерлы Совет карары белән расланган “Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә”гә яраштырып, карар бирәм:

1. “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын” 2019 елның 5 августына билгеләргә.

2. “Яңасала авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар”ны Арча муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт адресы буенча 2019 елның 5 августында 10.00 сәгатьтә үткәрергә.

3. Гражданнарның Яңасала авыл җирлеге муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрен һәм җәмәгать тыңлауларында катнашу турында язмача гаризаларын 5 августның 10.00 сәгатенә кадәр Арча муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 нче йорт адресы буенча җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) , Арча муниципаль районының рәсми сайтында(arsk.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 18 йорт; Каенсар авылы, урта урам, 25 нче йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерен торуны үз өстемә алам.

Яңасала авыл
җирлеге башлыгы Сафин А.И.

СОВЕТ ЯНГА-САЛСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН * АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН * МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ЯНГА-САЛСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ИНН 1609003024